ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 21 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында” 2005 елның 29 декабрендәге 134-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 3; 2013, № 5; 2014, № 5, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның җиденче абзацын үз көчен югалткан дип санарга;

2) 7 статьяда:
а) 3 өлештә:
беренче абзацта “Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару профессиональ хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару профессиональ формированиеләре” сүзләреннән соң “, тау-коткару эшләрен гамәлгә ашыручы һәлакәттән коткару профессиональ хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару профессиональ формированиеләреннән тыш,” сүзләрен өстәргә;
өченче абзацта “Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары каршындагы халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итү буенча махсус вәкаләтле идарә органнары белән килештереп” сүзләрен “федераль башкарма хакимият органының халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итү буенча махсус вәкаләтле территориаль органы белән килештереп, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итү

буенча махсус вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә” сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә “, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары каршындагы халыкны, территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итү буенча махсус вәкаләтле идарә органнары белән килештереп,” сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 8 статьяның 7 өлешендә “Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары каршындагы халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итү буенча махсус вәкаләтле идарә органы” сүзләрен “федераль башкарма хакимият органының халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итү буенча махсус вәкаләтле территориаль органы” сүзләренә алмаштырырга;

4) 9 статьяның 2 өлешендә “билгеләнгән тәртиптә” сүзләрен “башкарма хакимиятнең халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдә яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итү буенча махсус вәкаләтле федераль органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктыннан, 2 пунктның “а” пунктчасындагы өченче абзацыннан, 4 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты, 2 пунктның “а” пунктчасындагы өченче абзацы, 4 пункты 2018 елның 16 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты                                                                 Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 07 октябрь
№ 74-ТРЗ